**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЕРХНЕКАМЕНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
улица Дружба, дом 7, село Ибраево Каргали,
423108

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЮГАРЫ КӘМИНКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Дружба урамы, 7 йорт, Ибрай Каргали авылы,
423108

тел./факс (84396) 2-31-60/2-34-16 email: Vkam.Cmn2@tatar.ru

№ 15 05 август 2025 ел

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# КАРАР

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге территориясендә терекөмешле эшкәртелгән лампаларны җыю урыннары турында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 24.06.1998 № 89-ФЗ, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 10.01.2002 № 7-ФЗ, «Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 23.11.2009 № 261-ФЗ, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законнар нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җитештерү һәм куллану калдыкларын тиешенчә булмаган җыю, туплау, файдалану, зарарсызландыру, транспортировкалау һәм урнаштыру гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә эш итү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Югары Кәминкә авыл җирлегендә яшәүче терекөмешле лампаларны кулланучыларда эшкәртелгән терекөмешле лампаларның туплану урынын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Югары Кәминкә авылы, Дружба ур., 48 а йорты.
2. Чирмешән муниципаль районының Югары Кәминкә авыл җирлеге территориясендә әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында кулланылган терекөмешле лампалар туплау урыннарының

урнашуы турында, шулай ук мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мәгълүматны урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә.

3. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Югары Кәминкә авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге территориясендә терекөмешле эшкәртелгән лампаларны җыюны оештыру тәртибе турында» 2017 елның 29 маендагы 12 номерлы карарын;

- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге территориясендә терекөмешле эшкәртелгән лампаларны җыюны оештыру тәртибе турында» 2017 елның 29 маендагы 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 22 июлендәге 13 номерлы карары.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Югары Кәминкә авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н.Минһаҗев